УДК 377.1:730

***Т.Н. Кривошеева***

# КАЗАН СӘНГАТЬ МӘКТӘБЕНДӘ СКУЛЬПТУРА ДӘРЕСЛӘРЕ АЛЫП БАРУНЫҢ КӨНБАТЫШ ЕВРОПА ҺӘМ КӨНЧЫГЫШ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

Статья посвящена отражению традиций восточной и западноевропейской школ в преподавании скульптуры в казанской художественной школе на трех этапах ее истории. Первый этап – начало XX века, время основания школы до 1920-х годов, второй – середина XX века, он связан с деятельностью С. Ахуна, последний – настоящее время, деятельность отделений керамики и скульптуры в Казанском художественном училище им. Н.И. Фешина.

**Ключевые слова:** этнический, скульптура, преподавание, школа, пластика.

Казан сәнгать көллиятенең скульптура бүлегендә һәм В. Суриков исем. Мәскәү дәүләт архитектура һәм сәнгать институтының Казан филиалында хәзер скульпторларның яңа буынын – иҗади эш процессында, техник һәм матди мөмкинлекләрдән файдалана белү белән бергә, электән яшәп килгән тәҗрибәне дә, мәдәни киңлектә үзтәңгәллеккә ирешү юлларын да оста файдалана белүче сәнгатькәрләрне әзерлиләр. Татар скульптурасының тарихи язмышы җиңел булмый: озакка сузылган дини һәм идеологик карашлар хөкем сөргән кырыс заманнарда иҗади процесслар бөтенләй туктап тора. Стиль формалаштыручы ике төп юнәлеш – академик реализм (Европа мәктәбе) һәм этник кушылмалар (Көнчыгыш, «төркиләргә кадәрге») хакында киңрәк тукталып үтү урынлы булыр. XX гасыр башында Республикада скульптур белем бирүнең кабатланмас үзенчәлеге һәм яңалыгы белән аерылып торган беренче омтылыш Казан сәнгать мәктәбенең (КСМ) скульптура бүлегендә ясала, ул Петербург сәнгать академиясендә пластика укыту тенденцияләрен хәтерләтә. Бу чорда бүлек эшчәнлегенә укытучылардан П. Дзюбанов белән В. Богатырев зур өлеш кертәләр [Кривошеева, 2006].

1917 елгы Октябрь борылышыннан соң Казан сәнгать-педагогика техникумында (КСМнең шул еллардагы исеме) укытуны халык хуҗалыгы өчен яраклаштырылган гамәли сәнгать юнәлешендә алып барырга тәкъдим ителә. Сәнгать белеме бирү буенча методик комиссия утырышында «ялгыз талантлар турында түгел, ә массакүләм гомуммәдәният хакында уйларга кирәк» дип чыгыш ясыйлар. 1927 елда КСМ Казан берләштерелгән сәнгать-театр техникумы буларак эшли. Методик комиссия утырышларының берсендә архитектура-сәнгать курсларында «совет» уенчыклары әзерләү мәсьәләсе дә күтәрелә.

1937 елда Казан сәнгать көллиятендә скульптура укытучысы булып Садри Ахун эшли башлый. Ул анда Урал сәнгать техникумын, аннан соң Сәнгать академиясен (А. Матвеев мастерское буенча) тәмамлагач килә. Садри Ахун, татар сынлы сәнгатендә, беренчеләрдән булып, әвәләп кеше сынын ясый, портретларны һәм җәнлек рәсемнәрен академик традицияләргә нигезләп иҗат итә.

Садри Ахун Казан сәнгать көллиятендә 1952 елга кадәр эшли. Бу уку йортында скульптура бүлеге фәкать 1948 елда гына оеша. Нәкъ менә шул елдан анда Н. Адылов, В. Маликов, Р. Нигъмәтуллина укый. Алар соңыннан Совет рәссамнары берлегенең татар бүлеге профессиональ секциясендә үзәк фигураларга әвереләләр. Казан сәнгать мәктәбеннән В. Богатырев киткәннән соң бу бүлектә академик скульптура буенча белем бирүнең икенче этабы башлана.

Ул елларда скульптур композицияләрнең стиле мәдәнияттә хакимлек иткән «социалистик реализм» методына нигезләнә.

XX–XXI гасырлар чигендә Татарстанда мәдәният-сәнгать мәҗбүри кануннардан азат ителә һәм татар скульпторларының һәркайсына иҗади үзенчәлекләрен сәнгатьтә тулысынча гәүдәләндерергә мөмкинлек туа, һәм алар аннан уңышлы файдаланалар да. XXI гасыр башында Казан сәнгать көллиятендә пластика укытуны яңартып җибәрү омтылышы уяна. Ул – көллиятне К. Маркс урамындагы Казан сәнгать мәктәбенең архитектор К. Мюфке проекты буенча махсус эшләнгән бинасына күчерү вакыйгасы белән дә бәйләнә. Аңа кадәр әлеге бина анда урнашкан Казан авиация институтыннан сәнгати керамика бүлеге өчен, һөнәрханә (мастерской) буларак, арендага алынган була. Анда студентлар, рәсемнәр һәм картиналар ясаудан тыш, декоратив скульптура, балчыкны әвәләп һәм төрле формадагы калыпларга салып әйберләр эшләү белән шөгыльләнәләр. Бу бүлекнең эшчәнлеге пластика укытуның яңа этабында калыплап сәнгать әсәрләре эшләүне башлап җибәрүдә генә түгел, скульптур композицияләрнең этник-милли символларын аңлап иҗат итүдә дә зур әһәмияткә ия. XX гасырның соңгы утыз елында Көнбатыш Европа һәм Россиянең мәдәни киңлегендә сәнгатьнең башка юнәлешләрен эзләүнең яңа формалары (модернизмга каршы буларак постмодернизм) барлыкка килде. Татарстанның мәдәни тормышы пластикасында бу, барыннан да элек, җирле архетипта, борынгы мәҗүсилек һәм мөселманлык үзенчәлекләрендә чагылыш тапты. Скульптура үсеше ыруглык үзенчәлекләрен саклаган хәлдәге яңа формалар ала. Казан сәнгать көллиятенең нәфис керамика бүлеге композицион әсәрләр тудыруда крайдагы борынгы фигуратив һәм орнаменталь мотивларга таяна. Декоратив материал буларак керамика бакча-парк пластикасының да, кечерәк формаларның да скульптур чишелешен хәл итәргә мөмкинлек бирә. Шуңа күрә керамика бүлегендә белем алучылар,

академик кысалар белән генә чикләнмичә, стильләштерүнең сәнгати чагылыш мотивларыннан һәм ысулларыннан иркен файдаланалар. Бу өлкәдә студентларның курс эшләреннән З. Гәрәеваның «Татар малае» («Татарский мальчик»), Р. Сабировның «Өзлексез хәрәкәттәге тормыш» («Жизни круговорот»), «Алтынурдачылар» («Золотоордынцы»), Т. Зәбировның «Тәкә» («Баран») һәм диплом эшләреннән З. Гәрәеваның «Өзлексез берләшү» («Бесконечное единение»), Т. Зәбировның «Үгезләр» («Быки») фигуралары аеруча кызыклы иҗат ителгән. З. Гәрәеваның «Татар малае» таш скульптураны хәтерләтә, аның аскы өлеше махсус рәвештә өскесеннән кыскарак эшләнгән: билдән җилкәгә кадәр ара, киресенчә, озынайтылган. Гомумән алганда фигура нәфис итеп, үсмерләрчә озын муенлы итеп ясалган. Малай мәдрәсә яки шул чор мәктәбе киеменнән; кайбер детальләре рельефлап әвәләнгән, икенчеләре исә тирән эзләр калдырып тырналгансыман. Батып торган эзләргә фирәзә төсен хәтерләткән бакыр окисе белән эмаль тутырылган. Ә шул ук авторның «Өзлексез хәрәкәттәге тормыш» композициясе берничә элементны берләштерә: ат, кулларын баш өстенә түгәрәкләп куйган алиһә-хатын һәм кошлар. Бу фигуралар борынгы керамик сфероконуслардагы атларны символлаштырган графиканы хәтерләтә, тик аның линияләре киң һәм аларга персонажлар өстәлгән. Шунысы кызык, студент бу эшен жгут техникасы нигезендә (чүлмәкне түгәрәкләп эшләүнең техник ысулын белмәгән чордагыча) эшләгән. Р. Сабировның «Алтынурдачылар»ы кыяга охшатылган таш скульптура стилендә иҗат ителгән. Кайсы яктан карасаң да тәэсирле булып күренә (фронталь итеп эшләнмәгән). Тасвирланышы белән ул артык аерылып тормый, архитектур яктан тыйнак һәм шактый нык буялган, автор бизәкләрне авангард стилендәрәк төшергән, форма бирүче линияләр һәм график таплар кулланган. Т. Зәбировның анималистик скульптуралары – «Тәкә» дә, «Үгезләр» дә уртак пластик чишелешләргә ия, гәрчә беренчесе – өстәлгә куярлык масштабта, икенчесе бакча-парк пластикасына нигезләнсә дә. Бу ике фигурада да хайваннарның гәүдәләнеше ачык детальләргә һәм бизәкләргә бай. Әйтик, тәкәнең кара ярымшарсыман өлешенә уелып алтынсу соляр (кояшсыман) тамгалар төшерелгән, стильләштерелгән башы белән мөгезе дә шундый ук характердагы орнаментлар белән бизәлгән.

Казан сәнгать көллиятенең скульптура бүлегендә укытуны бөтенләй яңача алып бару, 2001 елдан башлап, скульптор һәм укытучы А.М. Миңнуллина исеме белән бәйле. Ул бүлекнең матди базасын бөтенләй яңарта. Көллияттә, әкренләп, заманча станоклар, эш кораллары, балчык, гипс барлыкка килә. Скульптура остаханәсе (мастерское) шактый вакыт эшләми торганга, аның программасы да, педагогик ысуллары да яңабаштан үзгәртелә. Шулай да беренче чыгарылыш диплом ияләренә Сән-

гать академиясенең XX гасыр башындагы укыту алымнарын да, шул ук вакытта яңа методика нигезләрен дә узарга туры килә. А.М. Миңнуллина үзенең өченче ел яңача эшләү дәверендә инде бүлек укучыларының чын осталарча, профессионалларча иҗат итү алымнарын үзләштерүләренә ирешә. Студентларның эшләре имтихан комиссиясенең югары бәясен ала, һәм аларның иҗади хезмәтләре теләсә кайсы күргәзмәләр залында профессиональ осталарныкы белән ярыша алырлар иде. А.М. Миңнуллина методикасы студентларның дөньяви киңлектәге пластик сәнгать үрнәкләрен үзләштерүенә, борынгы скульптура әсәрләренең эчке архитектоникасын, форма төзелешен аңлап иҗат итүенә ирешүне күздә тота. Гомумән, Казан сәнгать көллиятендә скульптура буенча заманча укытуның нигезен бүген дә Сәнгать академиясендә XX гасыр башында кулланылган принциплар – борынгы үрнәкләрне өйрәнү, сюжет белән теманың беренчелегенә төшенү, образларны чынбарлыктагыча гәүдәләндерү тәшкил итә. 2006 елдагы диплом эшләре арасында Ф. Вәлиуллинның «Яшьлек» («Юность»), С. Ненароковның «Зәңгәр яулык» («Синий платочек»), Ф. Миңнебаевның «Әти» («Отец»), З. Мөхәммәдьянованың «Авыр әңгәмә» («Трудный разговор») иҗатлары аерым игътибарга лаек.

Ф. Вәлиуллин композициясендә яшьлек һәм җайдак темасы күтәрелгән, Җайдак – татар халкының яраткан персонажларының берсе, ә атка атланган егет, К. Петров-Водкин образына аваздаш булып, хыял, өметләр, якты киләчәк хисләре уята. Ат белән бәйле композиция башлап иҗат итүче скульптор өчен җиңел эш түгел, ә бу очракта автор аны уңышлы башкарып чыккан. З. Мөхәммәдьянова да ике фигуралы катлаулы композицияне җиңеп чыккан. Кыз белән егет фигуралары архитектоник яктан эчке киеренкелек халәте тудыра. Бер-берсенә каратып бастырылган фигуралар, скульптураның кайсы ягыннан гына карасаң да, үзара бәхәсле сөйләшүнең яңа ракурсын ачыклыйлар. «Әти» һәм «Зәңгәр яулык» әсәрләренең икесендә дә ялгыз утыручы фигуралар гәүдәләндерелгән. Эскәмиядә утыручы өлкән кеше скульптурасы тынычлыктан канәгатьләнеп калган картны хәтерләтә. Икенче скульптура хәрәкәтне – сугыш кыры тынып торган арада гармунда уйнаучы сугышчыны тасвирлый, ул «тальянкасын» тартып җибәргән халәттә гәүдәләндерелгән.

Димәк, композицион эшләрнең гәүдәләндерү рәвешеннән чыгып, Казан сәнгать көллиятендә скульптура укытуның ике төп юнәлешен аерып карарга була икән. Аның берсенең нигезен мифологик үзенчәлекләрдә дә чагылыш тапкан төрлелеккә, символлыкка, тамгалылыкка ия этник пластика тәшкил итә. Икенчесе – В. Суриков исем. Мәскәү дәүләт архитектура һәм сәнгать институтының Казан филиалында скульптура укытуда кулланылган реализм юнәлеше. Монысы инде гипербола һәм гротесклардан азат, аның

бурычы укучыларны һәрнәрсәне тормышчан итеп һәм әдәбипсихологик нигездә сурәтләү осталыгына өйрәтүдән гыйбарәт. Бүген заман сәнгатендә бер генә юнәлештә иҗат итү мөмкин түгел, дөньякүләм һәм рус сәнгатенең авангардизм агымы мәдәниятләрне гомумиләштерүгә (синтезлауга) юл ачты, ягъни бер үк әсәрне иҗат иткәндә борынгы этник стильләр дә, Европа-рус мәктәбе алымнары да үрелеп бирелергә мөмкин.

***Кривошеева Татьяна Николаевна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты,*
*Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы*
*email: krita06@mail.ru*